**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 13** **26. 02. 2026 ел.**

**"Физик затлар мөлкәтенә салым турында"**
**2014 елның 11 ноябрендәге 218 номерлы**
**Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге**
**Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 14 ноябрендәге 218 номерлы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрьдәге 253 номерлы, 2018 елның 07 ноябрендәге 171 номерлы, 2019 елның 20 мартындагы 195 номерлы , 2019 елның 05 ноябрендәге 215 номерлы, 2020 елның 07 августында карарлары редакциясендә ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 4 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Салым салу объектларының, кадастр бәясе, проектлана торган күпфатирлы йорт булган тәгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш, һәркайсының 300 миллион сумнан артып китсә;”

2) Карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагала.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Сәвәләй авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары** **С.К.Маклаков**